Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Бишмунча авыл Советы
КАРАРЫ

17 июль 2020 ел № 97

Җирле органнар вәкаләтләрендәге җирле үзидарә әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча барлыкка килә торган йөкләмәләрне хәл итү өчен, чыгым йөкләмәләрен уртак финанслау максатларында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына убсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмә

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 9 һәм 142.3 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 65 статьясындагы 5 өлеше, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге бюджет процессы турындагы нигезләмә нигезендә

Бишмунча авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Җирле органнар вәкаләтләрендәге җирле үзидарә әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча барлыкка килә торган йөкләмәләрне хәл итү өчен, чыгым йөкләмәләрен уртак финанслау максатларында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезләмә расларга (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» халыкка җиткерергә (PRAVO.TATARSTAN.RU), торак пунктлар территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә: Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Бишмунча авылы, Совет урамы, 57 нче а йорт, Кама-Елга авылы, Кама-Елга урамы, 26 а йорт, Бакчасарай авылы, Җиләкле урамы, 1 йорт, Ак-Чишмә авылы, Ак-Чишмә урамы, 1 йорт һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Бишмунча авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән) үз көченә керә.

Бишмунча авыл
җирлеге башлыгы Р.Г.Фазлыев

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Бишмунча авыл
Советының 2020 елның
17 июлендәге 97 номерлы
карарына 1 нче кушымта

Җирле органнар вәкаләтләрендәге җирле үзидарә әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча барлыкка килә торган йөкләмәләрне хәл итү өчен, чыгым йөкләмәләрен уртак финанслау максатларында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында
Нигезләмә

1. Гомуми наигезләмә

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 9 һәм 142.3 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 65 статьясындагы 5 өлеше, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге бюджет процессы турындагы нигезләмә нигезендә кабул ителгән әлеге Нигезләмә, җирле органнар вәкаләтләрендәге җирле үзидарә әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча барлыкка килә торган йөкләмәләрне хәл итү өчен, чыгым йөкләмәләрен уртак финанслау максатларында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына субсидияләр бирү тәртибе (алга таба - субсидия) һәм шартларын билгели.

2. Субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары

2.1. Субсидия җирле органнар вәкаләтләрендәге җирле үзидарә әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча барлыкка килә торган йөкләмәләрне хәл итү өчен, чыгым йөкләмәләрен уртак финанслау максатларында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына:

1) җирлекнең җирле үзидарә органнарының финанс-хуҗалык эшчәнлеген тәэмин итә торган муниципаль учреждениеләрне тоту буенча.

2.2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына субсидия бирү Бишмунча авыл җирлеге бюджеты керемнәре нисәбеннән гамәлгә ашырыла.

2.3. Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге бюджетыннан Әлмәт муниципаль районы бюджетына субсидияләр бюджетлар керемнәре классификациясе нигезендә Әлмәт муниципаль районы бюджетының керем өлешендә чагыла.

2.4 Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына субсидияләр күләме әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада күрсәтелгән методика нигезендә башкарыла.

2.5. Субсидия күләме чираттагы финанс елына Бишмунча авыл җирлегенең

бюджеты турындагы карарында, яисә чираттагы финанс елына Бишмунча авыл җирлегенең бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү юлы белән план чорына һәм Бишмунча авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр кертү юлы белән раслана.

2.6 Бишмунча авыл җирлеге бюджетыннан Әлмәт муниципаль районы бюджетына субсидияләр, чираттагы финанс елына һәм план чорына расланган сумма чикләрендә Бишмунча авыл җирлеге карары нигезендә бирелә. Авыл җирлеге бюджетыннан Әлмәт муниципаль районы бюджетына субсидияләр чираттагы финанс елына һәм план чорына Бишмунча авыл җирлегенең бюджеты турындагы карар белән расланган сумма чикләрендә һәм Бишмунча авыл Советының карары нигезендә бирелә.

2.7. Бишмунча авыл җирлеге бюджетыннан Әлмәт муниципаль районы бюджетына субсидияләр Бишмунча авыл җирлеге башкарма комитеты һәм Әлмәт муниципаль районының башкарма комитеты арасында (әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта) төзелгән килешүләр нигезендә бирелә.

2.8. Әлмәт муниципаль районы бюджетына Субсидия бирү турындагы килешүдә түбәндәге нигезләмәләр булырга тиеш:

1) Субсидиянең максатчан билгеләнеше;

2) Субсидияләрне бирү һәм тоту шартлары;

3) Субсидия бирүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләме;

4) Субсидияләрне күчерү тәртибе;

5) Субсидияләр бирү һәм тоту өчен билгеләнгән шартларның үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибе;

7) Финанс белән тәэмин итү чыганагы Субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе;

8) башка шартлар.

2.9. Килешүләр төзү тәртибе Бишмунча авыл җирлеге Уставы һәм Бишмунча авыл Советы норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

2.10. Субсидия бирү турында килешү проектын әзерләү Әлмәт муниципаль районы бюджетына бюджет чараларын төп бүлүче булып торучы һәм Субсидия күчерүне башкаручы Бишмунча авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.11. Бишмунча авыл җирлеге бюджетыннан Әлмәт муниципаль районы бюджетына субсидияләр килешү төзегәннән соң 15 көн эчендә, җирле бюджетның салым һәм салым булмаган керемнәре буенча план билгеләрен үтәгәндә, я бюджетның керем өлешен фактта үтәүне исәпкә алып, агымдагы елның 1 декабрьдән дә соңга калмыйча күчерелә.

2.12. Бишмунча авыл җирлеге бюджетыннан Әлмәт муниципаль районы бюджетына субсидияләр, касса рәвешендә үтәүче органда ачылган Әлмәт муниципаль районы бюджетының бердәм счетына акча күчерү юлы белән Әлмәт муниципаль районы бюджетына күчерелә.

2.13. Чираттагы финанс елның 1 гыйнварына файдаланылмаган Субсидияләрнең калдыклары буенча операцияләр (Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242 статьясының 5 пункты нигезендә):

1) Агымдагы финанс елның 1 гыйнварына Бишмунча авыл җирлеге бюджетыннан Әлмәт муниципаль районы бюджетына күчерелгән һәм максатчан билгеләнешләре булган Субсидияләр кулланылмаганда, агымдагы финанс елының 15 эш көне дәвамында, җирлекнең бюджет керемемә кайтарылырга тиеш.

2) Бишмунча авыл җирлеге средстволарын төп бүлүче булып торган администратор тарафыннан, Субсидияләр турындагы пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгәнчә, агымдагы финанс елында кулланылмаган, шулай ук аларны Әлмәт муниципаль районы бюджетына кайтару, аларның кирәклеге турындагы карар кабул

ителгәнче, 30 эш көненнән дә соңга калмыйча Бишмунча авыл җирлеге бюджетында күрсәтелгән, Әлмәт муниципаль районы бюджеты чыгымнары турында хисап нигезендә, килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм формада төзелгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы күрсәтелгән Субсидияләр.

3) Бишмунча авыл җирлеге бюджет средстволары баш администраторының Бишмунча авыл җирлеге бюджетыннан Әлмәт бюджетына күчерелгән субсидияләргә ихтыяҗ булу турындагы карары нигезендә, финанс органы белән билгеләнгән тәртиптә, максатчан кулланылмаган, финанс органы белән килештерелгән максатчан билгеләнеше булмаган муниципаль район бюджеты чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итү өчен агымдагы финанс елында Әлмәт муниципаль районы бюджеты кеременә кире кайтарылырга мөмкин.

4) Әлеге пунктның 3 пунктчасында каралган карарлар кабул итү тәртибе җирле бюджетлардан бюджетара трансфертларны кире кайтару тәртибен җайга сала торган җирле администрациянең муниципаль хокукый актлары белән билгеләнә.

5) 1 гыйнварга кадәр файдаланылмаган Субсидияләр Бишмунча авыл җирлеге бюджеты керемена күчерелмәгән очракта, күрсәтелгән акчалар Бишмунча җирлеге бюджеты керемена Россия Федерациясенең бюджет законнары белән билгеләнгән тәртиптә түләтелергә тиеш.

2.14. Субсидияләр түбәндәге очракларда Бишмунча авыл бюджетына кайтарылырга тиеш:

- аларны максатчан файдаланмауны ачыклау;
- Әлмәт муниципаль районының хисаплылыгын тапшырмау;
- хисапта дөрес булмаган белешмәләр тапшыру.

2.15. Әлмәт муниципаль районы субсидияләрен ирекле тәртиптә кире кайтармаган очракта, әлеге акчалар Бишмунча авыл җирлеге бюджетына закон белән билгеләнгән тәртиптә түләттерелергә тиеш.

## 3. Субсидияләрдән файдалану буенча контроль һәм хисап

3.1. Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә органнары Бишмунча авыл җирлеге бюджетыннан алынган субсидияләрдән максатчан файдалану һәм алардан файдалану турындагы хисапларның дөреслеге өчен җаваплы.

3.2. Субсидияләрдән файдалануны тикшереп торуны Бишмунча авыл җирлеге башкарма комитеты һәм Әлмәт муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы гамәлгә ашыра.

3.3. Субсидияләрдән файдалану турында хисап Бишмунча авыл җирлегенә Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм формада тапшырыла

Бишмунча авыл җирлеге башлыгы — Р.Г.Фазлыев

Җирле органнар вәкаләтләрендәге
җирле үзидарә әһәмияттәге мәсьәләләрне
хәл итү буенча барлыкка килә торган
йөкләмәләрне хәл итү өчен, чыгым йөкләмәләрен
уртак финанслау максатларында Татарстан
Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Бишмунча авыл җирлеге бюджетыннан
Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы бюджетына субсидияләр бирү тәртибе
һәм шартлары турында Нигезләмәгә 1 нче кушымта

Җирле органнар вәкаләтләрендәге
җирле үзидарә әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча барлыкка килә торган йөкләмәләрне хәл итү өчен, чыгым йөкләмәләрен уртак финанслау максатларында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына субсидияләр күләмен исәпләү методикасы

Әлеге методика җирле органнар вәкаләтләрендәге җирле үзидарә әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча барлыкка килә торган йөкләмәләрне хәл итү өчен, чыгым йөкләмәләрен уртак финанслау максатларында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына субсидияләр күләмен исәпләү өчен кулланыла.

1. Әлмәт муниципаль районының җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Бишмунча авыл җирлеге бюджетыннан Әлмәт муниципаль районы бюджетына субсидияләр күләме җирлекнең җирле үзидарә органнарының финанс-хуҗалык эшчәнлеген тәэмин итүче муниципаль учреждениеләрне тоту буенча барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында җирле бюджетның план ассигнованиеләре һәм касса чыгымнары аермасыннан чыгып, Бишмунча авыл җирлегенең финанс-хуҗалык эшчәнлеген 2020 елның 1 июненә карап тотуны тәэмин итүче хезмәткәрләрнең хезмәтенә бухгалтерлык хезмәте күрсәтүне тәэмин итүче хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү өчен билгеләнә.

1.1. Бишмунча авыл җирлеге бюджетыннан Әлмәт муниципаль районы бюджетына җирле үзидарә органнарының финанс-хуҗалык эшчәнлеген тәэмин итә торган муниципаль учреждениеләрне карап тоту буенча Әлмәт муниципаль районының җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен уртак финанслау максатларында субсидияләр түбәндәге формула буенча билгеләнә**:**

$$S = ФОТ_{пл.} – (Р_{общ.} + Р_{доп.}),$$

кайда :

S - Әлмәт муниципаль районы бюджетына җирлек бюджетыннан бирелә торган Субсидия күләме;

ФОТпл - 2020 елның 1 июненә торышы буенча җирлекнең финанс - хуҗалык эшчәнлегенә бухгалтерлык хезмәте күрсәтүне тәэмин итүче хезмәткәрләргә хезмәт

өчен түләүнең планлы фонды;

Робщ - 2020 елның 1 июненә торышы буенча җирлекнең финанс - хуҗалык эшчәнлегенә бухгалтерлык хезмәте күрсәтүне тәэмин итүче хезмәткәрләр исәпләгән хезмәт хакына җирлек бюджетының касса чыгымы;

Рдоп. - җирлекнең финанс - хуҗалык эшчәнлеген бухгалтерлык хезмәте күрсәтүне тәэмин итүче хезмәткәрләр белән хезмәт шартнамәләрен туктатканда (өзгәндә) җирлек бюджетының ахыргы исәпләвенә бәйле өстәмә чыгымнары.

Җирле органнар вәкаләтләрендәге
җирле үзидарә әһәмияттәге мәсьәләләрне
хәл итү буенча барлыкка килә торган
йөкләмәләрне хәл итү өчен, чыгым йөкләмәләрен
уртак финанслау максатларында Татарстан
Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Бишмунча авыл җирлеге бюджетыннан
Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы бюджетына субсидияләр бирү тәртибе
һәм шартлары турында Нигезләмәгә 2 нче кушымта

Җирле органнар вәкаләтләрендәге
җирле үзидарә әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча барлыкка килә торган йөкләмәләрне хәл итү өчен, чыгым йөкләмәләрен уртак финанслау максатларында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына субсидияләр алу өчен килешүнең типик формасы

«__» _____________ 20__ел. № ______________

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Бишмунча авыл җирлеге башкарма комитеты алга таба «җирлекнең башкарма комитеты» дип аталачак

______________________________________________________________________
(башкарма хакимият органы җитәкчесе вазыйфасының атамасы)

______________________________________________________________________,
(ФИО)

______________________________________________________________________,
(башкарма хакимият органы турында нигезләмә, ышанычнамә, боерык яисә вәкаләтләрне раслый торган башка документ)

нигезендә эш итүче бер яктан, алга таба «Район башкарма комитеты» дип аталучы Әлмәт муниципаль районының башкарма комитеты

______________________________________________________________________
(муниципаль хакимиятнең башкарма органы җитәкчесе яисә ул вәкаләт биргән зат вазыйфасының атамасы)

______________________________________________________________________
(устав, ышанычнамә яисә вәкаләтләрне раслый торган башка документ)

нигезендә эш итүче, икенче яктан, алга таба бергәләп сүз алып барылганда, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Совет карары нигезендә «Яклар» дип аталучы

__________________________________________________
(шәһәр, авыл җирлеге вәкиллекле органы исеме)

«___» _____________ № ___ «____________________________________»,
(шәһәр, авыл җирлегенең чираттагы бюджеты турындагы карар финанс елы һәм план чорына)

түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр.

1. Килешү предметы

1.1.Әлеге Килешүнең предметы булып 20___ елда Әлмәт муниципаль районы **Бишмунча** авыл җирлеге бюджетыннан бюджетлар чыгымнары классификациясе кодлары буенча җирле үзидарә органнарының финанс-хуҗалык эшчәнлеген тәэмин итүче муниципаль учреждениеләрне тоту буенча Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Әлмәт муниципаль районы **Бишмунча** авыл җирлеге бюджетына Әлмәт муниципаль районы **Бишмунча** авыл җирлеге бюджет чыгымнары классификациясе нигезендә субсидияләр бирү тора (алга таба - БК кодлары):

1.2 Бишмунча авыл җирлеге бюджет чараларын баш бүлүченең коды, ___________ бүлеге, ___________ бүлекчәсе,
максатчан статья ________________, чыгымнар төре _____________.

2. Әлмәт муниципаль районы ыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү, максатлар үтәлеше субсидияләр бирелә торган

2.1. Әлеге Килешү нигезендә Әлмәт муниципаль районы бюджетына Бишмунча авыл җирлеге бюджетыннан бирелә торган субсидиянең гомуми күләме түбәндәгеләрне тәшкил итә:

2020 елда ____________ (____________________) сум _______ тиен.

3. Субсидия бирү тәртибе, шартлары һәм аны күчерү сроклары

3.1. Субсидияләр Бишмунча авыл җирлеге бюджет ассигнованиеләре чикләрендә, финанс елына һәм 20____ -20____ еллар план чорына Бишмунча авыл җирлеге бюджетының җыелма бюджет язмасы турында Бишмунча авыл Советы карары нигезендә бирелә.

3.2. Субсидияләр түбәндәге шартларны үтәгәндә бирелә:

а) Әлмәт муниципаль районы бюджетында чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре булу, аларны үтәү максатларында әлеге Килешүнең 2.1 пунктында каралган күләмдә субсидияләр бирелә;

б) Әлмәт муниципаль районы тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә бәйле чыгымнарны гамәлгә ашыру;

в) Әлмәт муниципаль районы тарафыннан субсидиядән файдалану турында хисап бирү.

3.3. Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге бюджетыннан әлеге Килешүнең 1.1. пунктында күрсәтелгән чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен Әлмәт муниципаль районы бюджетына бирелә торган субсидияләрне күчерү, килешү төзелгәннән соң 15 көн эчендә, җирле бюджетның салым һәм салым булмаган керемнәре буенча планлы билгеләнүләрне үтәгәндә, яисә Бишмунча авыл җирлеге бюджетының керем өлешен фактта үтәүне исәпкә алып, бер үк вакытта, әмма агымдагы елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

4. Якларның үзара эшчәнлеге

4.1. Җирлек башкарма комитеты түбәндәге бурычларны үтәргә тиеш:

4.1.1. Агымдагы финанс елына бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә әлеге Килешүдә билгеләнгән Субсидия бирү шартлары үтәлгәндә һәм Әлмәт

муниципаль районы бюджетына субсидияләр бирүне тәэмин итәргә.

4.1.2. Районның башкарма комитеты тарафыннан әлеге Килешүдә каралган субсидия бирү шартларын һәм башка йөкләмәләрне үтәүне тикшереп торуны гамәлгә ашыру.

4.1.3. Субсидия бирү туктатылган очракта, район башкарма комитетына әлеге туктатылу сәбәпләре турында хәбәр итәргә.

4.1.4.Районның башкарма комитетына әлеге Килешүне үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча аңлатмаларны әлеге Килешүнең 4.4.1 пункты нигезендә Район башкарма комитеты мөрәҗәгать алган көннән алып 5 эш көне эчендә җибәрергә.

4.1.5. Россия Федерациясенең бюджет законнарында һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка йөкләмәләрне үтәргә:

4.2. Җирлекнең башкарма комитеты түбәндәгеләргә хокуклы:

4.2.1. Районның Башкарма комитеты тарафыннан Килешүдә каралган субсидияләрне һәм башка йөкләмәләрне үтәүне тикшереп тору өчен кирәкле документларны һәм материалларны, шул исәптән бухгалтерлык исәбе һәм район башкарма комитеты тарафыннан субсидияләр бирү шартлары үтәлешен тикшереп тору өчен кирәкле документларны соратып алырга.

4.2.2. Россия Федерациясенең бюджет законнарында һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка хокукларны гамәлгә ашыру:

4.3. Районның башкарма комитеты түбәндәге бурычларны үтәргә тиеш:

4.3.1. Әлеге Килешүнең 3.2 пунктында билгеләнгән субсидия бирү шартларын үтәүне тәэмин итәргә.

4.3.2. Халыкның башкарма комитеты таләпләрен үтәүне җирлек бюджетына акчаларны кире кайтару буенча тәэмин итәргә.

4.3.3. Электрон документ рәвешендә җирлек Башкарма комитетына субсидияләр чыгымнары турында, әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган кушымтасы нигезендә, субсидияләр алынган елның 20 гыйнварыннан да соңга калмыйча, әлеге Килешүгә кушымта нигезендәге рәвеш буенча хисаплар бирүне тәэмин итәргә.

4.3.4. Башкарма комитет Районның башкарма комитеты тарафыннан әлеге Килешүдә каралган субсидияләрне һәм башка йөкләмәләрне, шул исәптән бухгалтерлык исәбе күрсәткечләрен һәм район башкарма комитеты тарафыннан субсидияләр бирү шартларын үтәүне тикшереп тору өчен кирәкле документлар һәм материалларны бирүгә мөрәҗәгать алганда , әлеге Килешүдә каралган башка йөкләмәләрне, шул исәптән бухгалтерлык исәбе күрсәткечләрен һәм беренчел документацияне бирергә.

4.3.5. Хисап елыннан соң килүче финанс елының 1 гыйнварына, субсидиянең калган өлешен Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән срокларда Бишмунча авыл җирлеге бюджетына кире кайтарырга.

4.3.6. Россия Федерациясенең бюджет законнарында һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка йөкләмәләрне үтәү:

4.4. Районның башкарма комитеты түбәндәгеләргә хокуклы:

4.4.1. Әлеге Килешүне үтәүгә бәйле рәвештә, җирлекләрнең башкарма комитетына аңлатмалар алырга.

4.4.2. Россия Федерациясенең бюджет законнарында һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка хокукларны гамәлгә ашыру:

## 5. Якларның җаваплылыгы

5.1. Әлеге Килешү буенча үз бурычларын үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта, яклар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

## 6. Йомгаклау нигезләмәләре

6.1. Әлеге Килешүне үтәүгә бәйле рәвештә, яклар арасында барлыкка килә торган бәхәсләр алар тарафыннан, мөмкин булганча, беркетмәләрне яисә башка документларны рәсмиләштерү белән сөйләшүләр үткәрү юлы белән хәл ителә. Килешүгә ирешмәгәндә, Яклар арасындагы бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.

6.2. Әлеге Килешү рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Әлеге Килешүгә Якларның һәркайсы исеменнән эш итәргә хокукы булган затлар тарафыннан имза салына һәм Якларның әлеге Килешү буенча үз йөкләмәләрен тулысынча үтәвенә кадәр гамәлдә була.

Әлеге Килешү предметы буенча яңа килешү төзелгән очракта, Якларның әлеге Килешү буенча йөкләмәләре туктатыла.

6.3. Әлеге Килешүне үзгәртү Яклар инициативасы белән гамәлгә ашырыла һәм әлеге Килешүгә карата өстәмә килешү рәвешендә рәсмиләштерелә.

6.4. Якларның үзара ризалыгы булганда әлеге Килешүне өзү мөмкин.

## 7. Якларның түләү реквизитлары:

| Авыл җирлеге исеме | Район исеме |
|---|---|
| Урнашу урыны: | Урнашу урыны: |
| Банк реквизитлары: | Банк реквизитлары: |
| БИК һәм Россия Банкы исеме<br>Расчетный счет<br>Лицевой счет<br>Шәхси счеты ачылган Федераль казначылыкның территориаль органы исеме<br>ИНН/КПП<br>ОГРН<br>ОКТМО | БИК һәм Россия Банкы исеме<br>Расчетный счет<br>Лицевой счет<br>Шәхси счеты ачылган Федераль казначылыкның территориаль органы исеме<br>ИНН/ КПП Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәре администраторы<br>ОГРН<br>ОКТМО<br>Керемнәрнең бюджет классификациясе коды, аның буенча район бюджетына кергән Субсидия акчалары исәпкә алына. |

## IX. Якларның имзалары

| Авыл җирлегенең кыскартылган исеме | Район җирлегенең кыскартылган исеме |
|---|---|
| _______________ / _________________<br>(имза) (инициалы, фамилия) | _______________ / _________________<br>(изма) (инициалы, фамилия) |

Җирле үзидарә әһәмияттәге сорауларны хәл итү буенча барлыкка килә торган йөкләмәләрне хәл итү өчен, чыгым чыгымнарын уртак финанслау максаталрында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына субсидияләр бирү турындагы Килешүгә 1 нче кушымта

Хисап
Әлмәт муниципаль районының Бишмунча авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының финанс-хуҗалык эшчәнлеген тәэмин итүче муниципаль учреждениене карап тоту буенча бюджеты чыгымнары турында хисап

Даимилек: еллык

Ед.изм. *Рублей*

| Чыгымнар юләлеше | Каралган средстволар | Фактта хисап датасына кергән | Фактта хисап датасына акча файдаланылган | Хисап датасына калган акча |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе _______________ _________________
*(имза)*

Финанс-бюджет палатасы рәисе____________ _______________
*(имза)*

Башкаручы _____________________________
*(Ф.И.О.,* вазыйфа, бүлекчә*)*